ИНСПЕКЦИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ
КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ | БОЕРЫК

10.01.2020 | Казан ш. | № 2

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2019 елның 17 октябрендәге 112 номерлы боерыгы белән расланган Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының $1^{1}$ һәм 2 өлешләрендә, $3^{2}$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең норматив хокукый актларын федераль законнарга яраштыру максатларында **боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2019 елның 17 октябрендәге 112 номерлы боерыгы белән расланган Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының 11 һәм 2 өлешләрендә, 32, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентына кертелә торган, әлеге боерык кушымтасында бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең хокук идарәсе юридик бүлегенә бу боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең җыелма анализ бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелеш күзәтчелеге
инспекциясенең 2020 елның
«10» гыйнварындагы 2 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2019 елның 17 октябрендәге 112 номерлы боерыгы белән расланган Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.4 пунктның унбишенче абзацында «басылып чыгу номеры: 0001201812280059» дигән сүзләрдән соң «, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып» сүзләрен өстәргә;

2 бүлектә:

2.5 пунктындагы «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе»;

3 бүлекнең 3.3.4.3 пунктында:

дүртенче абзацта «old.zakupki.gov.ru» сүзләрен «zakupki.gov.ru« сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «rnp.fas.gov.ru« сүзләрен «fas.gov.ru« сүзләренә алмаштырырга;

Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Форма Россия Төзелеш министрлыгының
№ 653/пр боерыгы белән расланган

Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә[1]

№_____________ «___» ____________ 20___ ел.

Төзүче оешманың атамасы:

_______________________________________________

Төзүче оешманың төп дәүләт теркәве номеры:

_______________________________________________

Төзүче оешманың шәхси тәңгәллек номеры:

_______________________________________________

Төзелеш проектының исеме:

_______________________________________________

_______________________________________________

Капиталь төзелеш объектының адресы:[2]

_______________________________________________

_______________________________________________

Төзелешкә рөхсәт № _________ бирелү датасы ____________________
Бирелде

_______________________________________________

(Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы исеме яки

_______________________________________________

төзелешкә рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы)

Әлеге бәяләмә төзүче оешманың

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе нигезендә күпфатирлы йорт(лар) һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә хокуклы булуын, шулай ук төзүче оешманың һәм төзелеш проекты турындагы проект декларациясенең (20__ елның «_»________ редакциядә) ярашлы булуы турында раслый

___________________________________________________________________

(төзелеш проектының исеме)

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль закон нормаларында билгеләнгән таләпләргә туры килә.

Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында белешмәләр әлеге бәяләмә кушымтасында китерелә.

Бәяләмә бирүгә
вәкаләтле зат__________________________________________________________

(вазыйфаның атамасы)

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

(Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), имза)

[1]»Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның 19 статьясындагы $2^{1-1}$ өлеше нигезендә күрсәтелгән статьяның $2^{1}$ өлешендә каралган бәяләмә (алга таба – бәяләмә) төзүче оешмага, торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасыннан файдаланып, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле имза белән имзаланган электрон документ формасында бирелә.

[2] Әлеге объект төзелешенә рөхсәт нигезендә капиталь төзелеш объектының адресы күрсәтелә.

Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында 20___ елның «__»__________ ____ номерлы бәяләмәгә кушымта

| Ярашлылык турында таләп | | Ярашлылык турында билге[1] |
|---|---|---|
| 1 | Төзүче оешманың проект документлары һәм проект документларына карата уңай экспертиза бәяләмәсе бар | |
| 2 | Төзүче оешмага карата юридик зат – төзүче оешманы ликвидацияләү процедуралары уздырылмый | |
| 3 | Юридик зат – төзүче оешмага карата «Бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшү турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, әлеге федераль законда күрсәтелгән очраклардан тыш, банкротлык турында эштә кулланылучы процедураларның берсе кертелүе турында арбитраж суды карары юк [2] | |
| 4 | Юридик зат – төзүче оешмага карата административ җәза чарасы сыйфатында аның эшчәнлеген туктату турында арбитраж суды карары юк | |
| 5 | Юридик зат – төзүче оешмага карата предметы капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору һәм мондый капиталь ремонтлау яки төзү, үзгәртеп кору һәм капиталь ремонт эшләрен оештыру яисә юридик зат – төзүче оешмадан торак урыннарын сатып алу өлкәсендә эшләр башкарудан, хезмәтләр күрсәтүдән гыйбарәт булган контрактларда яки шартнамәләрдә каралган йөкләмәләрнең аның тарафыннан үтәлүе өлешендә намуссыз тәэминатчылар (подрядчылар, башкаручылар) реестрларында 2 төзүче оешма (шул исәптән төзүче | |

| | | |
|---|---|---|
| | оешма – юридик затның бер кулдагы башкарма органы вазыйфаларын башкаручы зат) турында мәгълүматлар юк | |
| 6 | Юридик зат – төзүче оешмага (шул исәптән юридик зат – төзүче оешманың бер кулдагы башкарма органы вазыйфасын башкаручы затка) карата дәүләт мөлкәтендә яки муниципаль мөлкәттә торган җир кишәрлеген сату буенча аукционда, йә дәүләт мөлкәтендә яки муниципаль мөлкәттә торган җир кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукы буенча аукционда намуссыз катнашучылар реестрында мәгълүмат юк[4] | |
| 7 | Төзүче оешманың коллегиаль башкарма органы, төзүче оешманың коллегиаль башкарма органы әгъзасы булып торган зат, төзүче оешманың бер кулдагы башкарма органы (физик зат яки аның функцияләрен гамәлгә ашыра торган идарәче компания), яки төзүче оешманың бер кулдагы вакытлыча башкарма органы, яисә, әгәр ул төзүче оешманың бер кулдагы башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашырса, идарәче компаниянең бер кулдагы башкарма органы функцияләрен башкара торган зат, ахыр чиктә турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аша) корпоратив юридик зат – төзүче оешма белән идарә итә торган физик зат (капиталда катнашу өлеше 5% күбрәк), шулай ук төзүче оешманың баш бухгалтеры «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның $3^2$ статьясында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә[5] | |
| 8 | Проект декларациясен җибәрү датасына төзүче оешма һәм (яки) аның төп җәмгыяте яки бүлендек җәмгыяте тарафыннан төзелеше өлешле төзелештә катнашу турында төзүче оешма белән мондый күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзүдә катнашучыларның беренчесе белән өч һәм аннан күбрәк айга төзелгән шартнамәне дәүләт теркәвенә алу өчен тапшырылган проект декларациясендә күрсәтелгән өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган күпфатирлы йорт(лар)ны һәм (яки) күчемсез | |

| | | |
|---|---|---|
| | мөлкәтнең бүтән объект(лар)ын файдалануга тапшыру срогын бозу факты ачыкланмаган | |
| 9 | Төзүче оешма турында проект декларациясендә күрсәтелгән мәгълүмат Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килә [6] | |
| 10 | Проект декларациясендә күрсәтелгән төзелеш проекты турында мәгълүмат Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килә[4] | |

[1] Графа «туры килә» форматында тутырыла.

[2] Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, №43, 4190 ст.; 2019, №27, 3538 ст.

[3] Реестрларны алып бару «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, №14, 1652 ст.; 2019, №26, 3318 ст.) һәм «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №30, 4571 ст.; 2019, №18, 2194 ст.) нигезендә гамәлгә ашырыла.

[4] Реестрны алып бару Россия Федерациясе Җир кодексының 39.12 статьясындагы 28 һәм 29 пунктлары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, №44, 4147 ст.; 2019, №31, 4442 ст.) нигезендә гамәлгә ашырыла.

[5] «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 июнендәге 151-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 151-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, әлеге Федераль законның 1 статьясындагы 8 пунктының «г» һәм «д» пунктчалары үз көченә кергән көнгә кадәр, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе төзүче оешманың «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының 2 өлешендәге 1, 2-6 һәм 8 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү фактларын һәм (яки) проект декларациясе әлеге Федераль законның (151-ФЗ номерлы федераль закон редакциясендә) 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәгәнлеген ачыклаган очракта, бәяләмә бирүдән баш тартыла. Бәяләмә бирүдән башка нигезләрдә баш тарту рөхсәт ителми.

[6] «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның 20 статьясында билгеләнгән.

[7] «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның 21 статьясында билгеләнгән.